**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге Фома авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

«28» октябрь  2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның  28 октябрендә узган: «Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлегенең Фома авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән 1000 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган  акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне  хәл итүгә җибәрергә ризамы:

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгынга каршы инвентарь сатып алу; су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр башкару);
- Фома авылында урамнарны яктырту җайланмасы;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Фома торак пункты чикләрендә җирле әһәмиятле юлларны кышкы карап тоту) мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә җыенда катнашучы  сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 450 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 266 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 235 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 31 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлегенең Фома авылы торак пунктында гражданнар җыены узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлегенең Фома авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән 1000 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган  акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне  хәл итүгә җибәрергә ризамы:

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгынга каршы инвентарь сатып алу; су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр башкару);
- Фома авылында урамнарны яктырту җайланмасы;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Фома торак пункты чикләрендә җирле әһәмиятле юлларны кышкы карап тоту).» мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә  «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге Фома авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Р.Х.Абдрахманов

Фома авыл җирлеге башлыгы Р.Х. Абдрахманов